СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07.08.2020 Әгерҗе шәһәре № 49-10

2020 елга Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районының
муниципаль күчемсез мөлкәтен
хосусыйлаштыруның фаразлау планын
(программасын) раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль күчемсез мөлкәтен хосусыйлаштыруның кушымта итеп бирелгән фараз планын (программасын) расларга.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы федераль законнар таләпләре нигезендә 2020 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль күчемсез мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.
3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «2020 елга Әгерҗе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) раслау турында» 2020 елның 06 мартындагы 46-2 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга, шулай ук вакытлы матбугат басмасы - “Әгерҗе хәбәрләре” (“Агрызские вести”) район газетасында бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре, экология, табигый ресурслар һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы урынбасары,
Совет Рәисе урынбасары Р.Т. НУРИСЛАМОВ

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы Советының
07.08 2020 ел, № 49-10
карары белән расланган

**2020 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль күчемсез мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы)**

**I кисәк. 2020 елга муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру бурычлары**

2020 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль күчемсез мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) хосусыйлаштыруның фаразлау планы (алга таба - фаразлау планы) түбәндәгеләр нигезендә эшләнгән:

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон;

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2014 елның 13 октябрендәге 35-1 номерлы карары белән расланган "Әгерҗе муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турында" нигезләмәсе белән.

Муниципаль мөлкәткә идарә итү системасының базар икътисады шартларында төзелә торган өлеше буларак, 2020 елда муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның төп бурычлары Татарстан Республикасының «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары функцияләрен һәм бурычларын тәэмин итү өчен файдаланылмый торган муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру хисабына муниципаль милек структурасын оптимальләштерүдән, шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 159-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен гамәлгә ашырудан гыйбарәт.

2020 елда хосусыйлаштыруның төп максатлары булып тора:

- муниципаль милекне хосусыйлаштырудан Әгерҗе муниципаль районы бюджетына салым булмаган керемнәр керүне тәэмин итү;
- Әгерҗе муниципаль районы бюджетының керем өлешен арттыру;
- мөлкәт тотуга Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан чыгымнарны киметү.

Хосусыйлаштыру процессы нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге икътисадындагы структур үзгәрешләр көтелми, чөнки хосусыйлаштыруда тәкъдим ителгән торак булмаган бинада милекче

алышынганда «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә икътисади вәзгыятькә сизелерлек йогынты ясый торган житештерү урнаштырылмый.

Сатуга планлаштырыла торган барлык объектларның якынча бәясе, Фараз планы (программасы) нигезендә, хосусыйлаштыру базар бәяләвен үткәрү юлы белән төгәлләштерелергә тиеш.

2020 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган мөлкәт исемлеге, муниципаль милек структурасын алга таба оптимальләштерүне исәпкә алып, тулыландырылырга мөмкин.

**II кисәк. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең 2020 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган муниципаль мөлкәте**

| № | Объект | Адресы | Хосусыйлаштыру ысулы | Сатуның фаразланган вакыты | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | MITSUBISHI LANCER 1.6 автомобиле, иден.№ (VIN) JMBSNCS3A7U004581, көмешсу төстә | Әгерҗе ЦКС МБУК карамагында | ачык аукцион | 3 квартал | Билгеләнеше буенча кулланылмый |
| 2 | BMW 528i xDrive 2.0 автомобиле, иден.№ (VIN) X4XXH15440DW80733 ак төстә, 2012 елгы. | ТР Әгерҗе муниципаль районы Советы карамагында | ачык аукцион | 3 квартал | Билгеләнеше буенча кулланылмый |
| 3 | Hyundai Sonata 2.0 AT автомобиле, иден. № (VIN) KMHEB41BBCA34488 көмешсу төстә, 2011 елгы | ТР Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты карамагында | ачык аукцион | 3 квартал | Билгеләнеше буенча кулланылмый |
| 4 | Торак булмаган 1 катлы бина. | Татарстан Республикасы, Әгерҗе ш., Заводская ур., 31Г | ачык аукцион | 4 квартал | Билгеләнеше буенча кулланылмый |
| 5 | ТО пункты, 1 катлы | Татарстан Республикасы, Әгерҗе ш., Заводская ур., 31Г | ачык аукцион | 4 квартал | Билгеләнеше буенча кулланылмый |